Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-7**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 маддәсе 3 пунктының 3 пунктчасына туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1995 елның 9 февралендәге “Җир өчен аренда түләве турында”гы 74 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципальрайоны Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципальрайоны муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (теркәлә).

2.Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2006 елның 4 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир өчен аренда түләве турында”гы X-5 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 27 апрелендәге “Җир кишәрлекләре урнашуның уңайлы шартларын исәпкә алучы төзәтмә коэффициентын кулланмау турында”гы XXXVIII-3 номерлы карары.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 4 сентябрендәге
XXXIII-7 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Нигезләмә Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципальрайонымуниципаль милкендәге,Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 маддәсе 3 пунктының 3 пунктчасына туры китереп,аларны арендага бирүюридик һәм физик затларга, ялгызак эшмәкәрләргә торги үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибен гамәлгә кертә.

1.2.Әлеге Нигезләмә шулай ук җир кишәрлекләрен төзелеш өчен арендага бирү очракларына да (мондыйны аукционнарда бирү очракларыннан гайре) тарала.

1.3.Биналарның, корылмаларның бер өлешен арендага биргәндә бина, корылма торган җир һәм тоту өчен зарур булган,бу каралтыларның арендаланган мәйданнарына тигез бүлемтекләр өчен аренда түләве алына. Җир өчен аренда түләве бина яки корылмадан файдаланган өчен аренда түләвенә кертелә.

1.4.Җир салымын түләү буенча гамәлдәге законнар тарафыннан билгеләнгән ташламалар, җирле үзидарә органнарының норматив актлары белән билгеләнгән өстәмә ташламалар җирне арендага алучы гражданнарга һәм юридик затларга тарала.

1.5. Җир өчен аренда түләве буенча ташламасы булган арендатор тарафыннан җир кишәрлеге ташламасы булмаган затка субарендага бирелү очрагында субарендатор җир өчен аренда түләвен гомуми нигезләрдә кертергә бурычлы.

1.6.Җир өчен аренда түләве буенча ташламасы булмаган арендатор тарафыннан җир кишәрлеге ташламасы булган затка субарендага бирелү очрагында арендатор җир өчен аренда түләвен гомуми нигезләрдә кертә.

1.7. Аренда түләве җир кишәрлеген арендага биргән айдан соң килүче айдан башлап исәпләнә, шул исәптән төзелеш чорына, һәм арендатор тарафыннан ай саен кертелә.

## 2.Җир өчен аренда түләвенең зурлыгын билгеләү

2.1.Җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен еллык аренда түләвенең күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$А = Рс \times Кф,$$

биредә:

А – җир кишәрлеге өчен еллык аренда түләвенең күләме;

Рс - җир салымы ставкасының күләме;

Кф– җир салымы ставкасына җир кишәрлеген файдалану төрен исәпкә алучы әлеге Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән төзәтмә коэффициент;

2.2. 2001 елның 25 октябрендәге “Россия Федерациясендә Җир кодексын гамәлгә кертү турында”гы 137-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Закон) 3 маддәсенең 2 пункты нигезендә гамәлдәге Закон тарафыннан күздә тотылган тәртиптә даими (сроксыз) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштергәндә җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен еллык аренда түләвенең күләме Нигезләмәнең 2.1 пунктына таянып түбәндәге чикләрдә (артып киткән очракта – тигез) исәпләнелә:

арендаланган җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең ике проценты;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән арендаланган җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уннан өч проценты;

кулланыштанчыгарылган яки кулланышта чикләнгән арендаланган җир кишәрлекләре кадастр бәясенең бер ярым проценты.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципальрайоны
муниципаль милкендәге җир
кишәрлекләре өчен аренда түләве
күләмнәрен билгеләү тәртибе
турындагы Нигезләмәгә
кушымта

ҖИР КИШӘРЛЕГЕН ФАЙДАЛАНУ ТӨРЕН

ИСӘПКӘ АЛУЧЫ ТӨЗӘТМӘ КОЭФФИЦИЕНТЛАР

ИСЕМЛЕГЕ

| Җир кишәрлеген файдалану төре | Коэффициент |
|---|---|
| Авыл хуҗалыгы җитештерүенә | 1,0 |
| Торакка, шәхси ярдәмче хуҗалыкка, җиләк-җимеш үстерү бакчачылыгына, яшелчә үстерү бакчачылыгына һәм дача төзелешенә | 1,0 |
| Җитештерү өлкәсе объектларына | 1,0 |
| Электр станцияләрен, аларга хезмәт күрсәтү корылмаларын һәм объектларын урнаштыру өчен аталган объектларга | 1,0 |
| Портлар, су һәм тимерюлвокзалларын, автоюл вокзалларын, аэровокзалларны урнаштыруга аталган объектларга | 1,0 |
| Файдалы казылмалар чыгару өчен, тимер юлларны, ясалма төзелгән эчке су юлларын, причаллар, пристаньнар, тимер һәм автомобиль юл тармаклары зоналары, су юллары, трубопроводлар, элемтәнең кабель,радиореле һәм һава линияләре һәм радиофикация линияләре, электр тапшыруның һава линияләре, корылмаларның конструкциягә караган элементлары, җир өсте һәм җир асты биналары, каралтылары, корылмалары, транспорт, энергетика һәм элемтә җайланмаларын куллану, тоту, төзү,реконструкцияләү, ремонтлау, үстерү өчен зарур булган объектларны урнаштыру өчен аталган объектларга; спутник элемтәсенең җир өсте корылмаларын һәм инфраструктурасын, космик эшчәнлек объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән объектларга | 1,0 |
| Склад итептотылаторганобъектларга | 1,0 |

| | |
|---|---|
| Административбина, бүлмә һәм офисларга | 2,0 |
| Күмәртәле сәүдә объектларына | 4,0 |
| Җәмәгать туклануы объектларына | 4,0 |
| Ваклап сату сәүдәсе объектларына (кибетләр, сәүдә мәйданы булган павильоннар, данәләп сатыла торган товар сәүдәсе киосклары), базар, аптека объектларына | 10,0 |
| Гостиницаларга | 5,0 |
| Банк, иминият, биржаэшчәнлегеобъектларына ( шул исәптәнтүләү терминалларына) | 10,0 |
| Реклама объектларына (нигезгә урнаштырылган реклама такталары һәм стендлары) | 75,0 |
| Гаражларга | 1,0 |
| Ачык автомототранспорт тукталышларына | 3,0 |
| Автосервис һәмавтозаправкастанциясеобъектларына | 4,5 |
| Автомототранспорт өчен ябыккүпкатлыһәм җир асты тукталышларына | 1,0 |
| Автомототранспорт өчен ябыккүпкатлы тукталышлар төзелү чорына | 1,0 |
| Махсуслашкан тукталышларга (тоткарланган транспорт чаралары тукталышлары) | 0,1 |
| Чистарту корылмалары объектларына | 0,1 |
| Татарстан Республикасының 2004 елның 27 декабрендәге “Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында”гы 69-ЗРТ номерлы Законын тормышка ашыру максатларында төзелүче торак һәм объектлар төзелешенә | 0,1 |
| Гражданнар авиациясе объектларына | 0,1 |
| Спорт объектлары һәм корылмаларына | 0,17 |
| Рекреация һәм дәвалау-сәламәтләндерүгә аталган объектларга | 1,0 |
| Кулланыштагы су объектларына | 1,0 |
| Скверлар, паркларурнашканобъектларга | 1,0 |
| Башкаобъектларга | 2,0 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауучреждениеләрендә дәваланучы гражданнарга, аларны озатучы затларга вакытлыча бушлай тору өчен аталган объектларга | 0,1 |
| Медицина, социаль,психологик, юридик ярдәм күрсәтүгә аталган хәйрия фондлары биналары, каралтылары һәм корылмаларына (шул исәптән аларның төзелү чорына) | 0,01 |
| Оешуы, төзелеше, куллану, реконструкцияләү, моденирнизацияләве2005 елның 21 июлендәге “Концессион килешүләр турында”гы 115-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп төзелгән шартнамәләр, килешүләр нигезендә гамәлгә ашырылучы гидротехника корылмаларына ( су мохите тәэсиренә дучар була торган су ресурсларын файдалану һәм саклау, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын кире кайтару өчен аталган корылмалар, буаларны, су ыргыту, су кертү һәм чыгару корылмаларын кертеп; насос станцияләре; суднолар үтү шлюзлары; суднолар күтәрткечләр; су басулардан, сусаклагычлар, елга ярлары һәм елга юллары төпләрен җимерелүләрдән саклау өчен аталган корылмалар;дамбалар, яр ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары белән; пирслар; техник су белән тәэмин итү системасы корылмалары) | 0,1 |
| Россия ФедерациясеҖиркодексының 39.6 маддәсенең 2 пункты 3 пунктчасына туры китереп бирелгән һәмРоссия ФедерациясеҖиркодексының 39.6 маддәсенең 2 пункты 25 пунктчасына яки 2005 елның 21 июлендәге “Концессион килешүләр турында”гы 115-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп бирелгән җир кишәрлекләре белән ызан чикләре булган җир кишәрлекләрендә төзелгән объектларга | 0,1 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсенең 2 пункты 25 пунктчасына туры китереп төзелгән аренда шартнамәләре нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң үз һәм (яки) заем средстволары исәбенә торгызылган гидротехника корылмаларына ( су мохите тәэсиренә дучар була торган су ресурсларын файдалану һәм саклау, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын кире кайтару өчен аталган корылмалар, буаларны, су ыргыту, су кертү һәм чыгару корылмаларын | 0,1 |

| | |
|---|---|
| кертеп; насос станцияләре; суднолар үтү шлюзлары; суднолар күтәрткечләр; су басулардан, сусаклагычлар, елга ярлары һәм елга юллары төпләрен җимерелүләрдән саклау өчен аталган корылмалар; саклану корылмалары; дамбалар, яр ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары белән; пирслар; техник су белән тәэмин итү системасы корылмалары) | |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсенең 2 пункты 3 пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау объектларына | 0,5 (җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгән вакыттан алып 5 ел срокка) |